# ЭШ ДӘФТӘРЕ

гомуми башлангыч белем бирү укучыларында
коррупциягә каршы күзаллау
формалаштыру буенча



ББК 74.200.5
Э98

**Проектның җитәкчесе:** Хәмитов Р. Г., Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының ректоры, педагогика фәннәре кандидаты, доцент

**Фәнни редактор:** Руднева Я. Б., Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының фәнни һәм инновацион эшчәнлек буенча проректоры, тарих фәннәре кандидаты

**Автор-төзүчеләр:** Хәмитова Г. Р., Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының башлангыч һәм мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү кафедрасы мөдире, педагогика фәннәре кандидаты

Сәгъдиева И. Т., Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының башлангыч һәм мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү кафедрасы өлкән укытучысы

Мирошниченко Л. В., Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының мониторинг, экспертиза, белем сыйфатын бәяләү бүлеге башлыгы, педагогика фәннәре кандидаты, доцент

**Татар теленә тәрҗемә:** Шәмсетдинова Р. Р., Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты, доцент

Эш дәфтәре Татарстан Республикасының ике дәүләт (русча һәм татар телләрендә), башлангыч мәктәп укучыларының әхлакый-этик тәҗрибәсен формалаштыру үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән, коррупциягә каршы күзаллау формалаштыруга, дәрестән тыш чараларны һәм сыйныф сәгатьләрен оештыруга юнәлдерелгән.

**© ГАОУ ДПО ИРО РТ, 2016**

## Кадерле дустым!


Сине яхшылык һәм яманлык, намуслылык һәм намуссызлык, гаделлек һәм гаделсезлек, дуслык, татулык, ярдәмчеллек, риясызлыкның кыйммәте турында сөйләшүгә чакырабыз.

Укытучыларың, әти-әниең, дусларың белән бергәләп син безнең барыбыз өчен дә бик мөһим булган мәсьәләләр турында фикер алышырсың.


Син үз язмышыңа, туганнарыңның, үз шәһәреңнең, үз илеңнең язмышына битараф калмассың дип ышанабыз.

Син һәм синең дусларың «Тирә-ягыбыздагы тормыш гаделрәк, яхшырак булсын өчен нәрсә эшли алабыз?» – дигән сорауга җавап эзләрсез дип ышанып калабыз.


### Шартлы билгеләр




сорауга җавап бир



уйла



әти-әниең белән фикер алыш



дусларың белән фикер алыш



рәсем яса



уйлап тап

# 1нче класс


## «Дуслык һәм туганлык байлыктан кадерлерәк»

### 1нче дәрес. «Синең якын дусларың»



1. Рәсемнәрне игътибар белән кара һәм буя.





**2. Шигырьне укы.**


Дуслашасың киләме? Мин дусларга бик бай.
Бу менә Лилия дускай,
Бусы – утка тиң Сара, Талия дускаем да бар,
Монысы – Ания чыркылдык, бу – Сәвия матуркай,
Илсөя – озын толымлы, Арслан исә акыллы,
ә ярдәмчеле – Айдар.

**Сорауларга җавап бир:**

Шигырь ошадымы?


Ник балаларны утка тиң, акыллы, ярдәмчел дигән сүзләр белән атыйлар?

Синеңчә, дус нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?



**3. Чын дус нинди сыйфатларга ия булырга тиеш дип уйлыйсың? Шул сүзләрне кызыл карандаш белән әйләндереп ал.**

| | | |
|---|---|---|
| тыйнаклык | битарафлык | игелеклелек |
| намуслылык | гаделлек | ярдәмчеллек |
| көнчелек | эгоистлык | мактанчыклык |
| усаллык | яхшылык | саранлык |
| мин-минлек | аралашучанлык | |



**4. Әти-әниең белән бергәләп Г. Акуловның шигырен укы.**

Хорошо быть одиноким,
Если ты не одинок,
Хорошо, когда под боком
Есть и север, и восток,

Есть и запад осторожный,
Есть и теплый, тихий юг,
Когда рядом есть надёжный,
Бескорыстный, верный друг.

**«Бескорыстный» дигән сүзне татарчага тәрҗемә ит, сүзлектән мәгънәсен тап. Әти-әниеңнән бу сүзең мегънәсен язып куюларын сора.**

## 2нче дәрес. «Бер-береңә таяныч булсаң – бернәрсә дә куркытмый»

**1. Табышмакның җавабын тап. Җавабыңның рәсемен яса.**

Биш ир туган: тигезләр,
Ә үзләре буйга төрлеләр.

**2. Мәкальне җый.**

яхшы | – | азык | җанга | сүз

**3. Рөстәм Мингалимның «Дусларың гына булсын» шигырен укы.**

Егылсаң торып була,
Сөйләшеп, уйнап була,
Торсаң, йөгереп була,
Күп нәрсә белеп була,
Йөгерсәң, җитеп була –
Шаярып-көлеп була –
Дусларың гына булсын!
Дусларың гына булсын!

Син шигырь автораның фикерен белән килешәсеңме?


**Җөмләне дәвам ит.**

Әгәр минем дустым белән берәр күңелсез хәл булса, мин

## Знче дəрес. «Дустыма бүлəк»

**1. Е. Благининаның «Подарок» дип аталган шигырен укы.**

Пришла ко мне подружка,
И мы играли с ней.
И вот одна игрушка
Вдруг приглянулась ей:
Лягушка заводная,
Весёлая, смешная.
Мне скучно без игрушки –
Любимая была!
Но всё же я подружке
Игрушку отдала.



**Сорауларга җавап бир.**

Дустына уенчыгын бүлəк иткəннəн соң кыз нинди хислəр кичерə? Синең тормышыңда шуңа охшаш хəл булмадымы?

**2. Фикерлəрне укы. Үзең килешкəн фикерлəрне V тамгасы белəн билгелə:**

• Бүлəк – ул кешегə булган рəхмəтеңне белдерү, аны шатландыра, игътибарыңны күрсəтə алу мөмкинлеге.

• Сиңа ике бертөрле əйбер бүлəк иттелəр, син үзеңнең канəгатьсезлегеңне белдер.

• Бүлəклəренең кыйммəтлеме, арзанлымы булуына карамастан, кунакларга рəхмəтне бертөрле итеп əйтергə кирəк.

• Бүләкне елмаеп, матур сүзләр әйтеп бирергә кирәк.

• Үз кулларың белән ясаган бүләкне бирү дә, андый бүләкне алу да күңелле.


• Бүләкне битараф кыяфәт белән кабул итәргә һәм, рәхмәт әйтеп тормыйча, кырыйга алып куярга кирәк.

• Бүләк өчен рәхмәтле булырга кирәк.

• Бүләк ошамаса, бу турыда бүләк итүчегә әйтергә кирәк.

• Бүләк итеп бирелгән ризык белән барлык кунакларны сыйларга кирәк.

> «Әгәр дә синең бүләгең иясенә ошаса, димәк, син җаныңның бер өлешен аңа биргәнсең».
>
> Япон халык әйтеме



**3. Түбәндәге сораулар буенча әти-әниең белән фикер алыш. Кагыйдәләрне язып куй.**

Бүләкне дөрес итеп ничек бирергә?

________________________________________

________________________________________

________________________________________

________________________________________

Бүләкне дөрес итеп ничек кабул итеп алырга?

________________________________________

________________________________________


________________________________________

________________________________________

# 2нче класс

## «Кем яхшылык кыла, шуның тормышы да рәхәт була»

### 1нче дәрес. «Йөрәгеңне яхшы гамәлләр кылырга өйрәт»



**1. Дәвам ит**


Яхшылык ул ____________________________________________

________________________________________________________

________________________________________________________

________________________________________________________

Язган билгеләмәңне сүзлектә «яхшылык» төшенчәсенә бирелгән билгеләмә белән чагыштыр.



**2. Танылган педагог, язучы В. А. Сухомлинскийның «Саран малай» исемле нәсерен укы.**


Нәсер – әдәби жанрның бер төре булган әхлакый яки дини кыска хикәя

**Сорауларга җавап бир.**

Саранлык кешене бизиме?

Саран кешегә тирә-яктагыларның мөнәсәбәте ничек?

3. Бирелгән йөрәкчекләргә иң ягымлы, җылы сүзләрне язып чыгыгыз һәм үзегез теләгән кешегә әйтегез. Сезнең күңелләрдәге җылы хисләр башкаларга да күчсен.



# 2нче дәрес. «Игелек кыл»

**1. В. Сутеевнең «Гөмбә астында» («Под грибом») исемле әкиятен тыңла.**

Рәсемнәрне чагыштыр. Ничек уйлыйсың: гөмбә астында ни өчен барысына да урын табылды икән




В. Сутеев иллюстрациясе

**2. Яхшы кешегә хас сыйфатларны белдерүче сүзләрне кызыл төс белән әйләндереп ал.**


| | | |
|---|---|---|
| үкенү | ихласлылык | кызгану |
| гафу итү | юмартлык | яхшы күңеллелек |
| ярдәм | көнчелек | түбәнсетү |
| гаделлек | игелеклелек | сизгерлек |



**3. Бу атна дәвамында башкалар өчен өч яхшы эш эшләргә тырыш, мәсәлән:**

1. Энеңә, сеңлеңә яки иптәшеңә дәресләрен әзерләргә ярдәм ит.
2. Дустыңа, туганнарыңа, укытучыңа акчага сатып алынмый торган бүләк бир.
3. Алга таба инде үзең уйла! –


## 3нче дәрес. «Тормыш яхшылыклар кылу өчен бирелгән»



**1. Түбәндә бирелгән сүзләрне сайлап алып тиешле баганага яз. Әгәр дә таныш түгел сүзләр очраса, аларның мәгънәләрен сүзлектән кара.**

Ярату, битарафлык, кешеләр өчен борчылу, агрессивлык, гаделлек, нәфрәт, риясызлык, ялган, көнчелек, шәфкатьлелек, хыянәт, кызгану, эгоистлык, ваемсызлык, теләктәшлек, тупаслык, кайгырту.

| ЯХШЫЛЫК | НАЧАРЛЫК |
|---|---|
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |
| | |



**2. С. Брэйэрның «Яхшы малай» исемле әкиятен тыңла.**

**Сорауларга җавап бир.**

Малай ник елап җибәргән?


Аның урынында булсаң, син нәрсә эшләр идең?



**3. Игелеклелек турында үз кагыйдәңне уйлап тап һәм язып куй.**


Дусларың уйлап тапкан кагыйдәләрне тыңла. Шулар арасыннан үзеңә иң ошаганын сайлап алып яз.

Шул кагыйдәләрне бозмаска тырыш.



**4.** Син «эмблема»ның нәрсә икәнен беләсеңме? Эмблема – төшенчә, идеянең шартлы сурәте.

**Әти-әниең белән бергә игелекле эшләрнең символы булырлык эмблема уйлап тап һәм яса.**



# 3нче класс

## «Намусыңны яшьтән сакла»

### 1нче дәрес. «Ярый һәм ярамый»




**1. «Ярамый» һәм «Ярый» исемле нәни кешеләрне яса.**

Сиңа кайсысы ошады? Кайсысы мөһимрәк?




**2. «Ярамый» исемле кешене барлык кешеләргә ошарлык итеп яса. Ул нәрсәне тыя һәм ни өчен? Үзең уйлап тап.**



**3. Логик мәсьәләне чиш.**

Бер илдә ике шәһәр бар икән. Берсендә – бары тик дөресен сөйләүче кешеләр, икенчесендә бары тик ялган сөйләүчеләр яши. Алар бер-берсенә кунакка йөриләр, ягъни бу шәһәрләрнең икесендә дә дөресен сөйләүче кешене дә, ялганчы кешене дә очратырга мөмкин. Сез шул шәһәрләрнең берсенә килдегез, ди. Беренче очраган кешегә бер генә сорау биреп, үзегезнең дөресен сөйләүчеләр шәһәрендәме, әллә ялганчылар шәһәрендәме икәнлегегезне ничек белә алырсыз?

## 2нче дәрес. «Намуслылык бар нәрсәдән кыйммәтрәк»




**1. «Саранлык» («Жадность») дип аталган рус халык әкиятен тыңла.**

**Дусларың белән фикер алыш.**

Малайны намуслы гамәл кылырга нәрсә этәрә?

Синең тормышыңда шуңа охшаш хәл булганы бармы?

Шундый очракларда син үзеңне ничек тоттың?




**2. Мәгънәдәш (мәгънәләре буенча якын булган) сүзләрне сайлап ал, ни өчен сайлавыңны аңлат.**


| | | |
|---|---|---|
| эчкерсезлек | | яла ягу |
| ялган | | намуслылык |
| дөреслек | ДӨРЕС | дөрес булмау |
| уйлап | | чыгару |
| саф күңеллелек | ЯЛГАН | гаделлек |
| чынбарлык | | алдалау |
| икейөзләнеп кылану | | хаксызлык |




**3.** Син «Үз бурычыңны намус белән башкару» дигән әйтемне ничек аңлыйсың? Төрле һөнәр ияләре үз бурычларын ничек башкара?
**Рәсемнәрне игътибар белән кара һәм буя.**











**4. Җөмләне дәвам ит.**


Мин намуслы һәм дөрес булырга тырышам, чөнки

______________________________

______________________________

______________________________

## 3нче дәрес. «Үземнеке һәм кешенеке»




**1. Хикәяне укы. Ни өчен шулай килеп чыккан икән? Син ничек уйлыйсың?**

Бер малай үзенең уенчыкларын беркемгә дә бирми, икән. Аның тубы яки велосипеды янына берәрсе килә башласа, «Тимә, минеке!» дип кычкырырга тотына торган булган. Кышкы бер көндә бик күп кар яуган. Малайлар кардан ныгытма (крепость) төзергә уйлаганнар, эшкә тотынмакчы гына икәннәр, берзаман безгә таныш малайның тавышы ишетелгән: «Карга тимәгез, кар минеке!»


Икенче юлы, әлеге малайны очраткач, балалар инде кабаттан «Тимә, минеке!» дигән сүзләрне әйтер дип көткәннәр, әмма гаҗәпләнүләренә каршы:

«Сез нишләп минем белән уйнамыйсыз?» дигән сүзләрне ишеткәннәр һәм күзләрендә яшь күргәннәр.




**2. Ике баганада бирелгән өлешләрдән мәкальләр төзе. Бу мәкальләр аша халык нәрсә әйтергә теләде икән — шул турыда уйлап кара әле.**

| | |
|---|---|
| Кешенең мең тәңкәсеннән | үзенекеннән коры калган. |
| Үз акчасы булмаган | кеше көмешенә үрелмә. |
| Үз өлешеңне ташлап | үз бер тиенең яхшы. |
| Кешенекенә кызыккан к | еше кесәсендәгеген санар, |
| | ди. |



**3. Сорауларга җаваплар яз.**


- \- Барыбызга да таныш булган мәкаль йөз сум акча урынына нәрсә тәкъдим итә? ________________
- \- Кеше кесәсендәге нәрсәне санау яхшы түгел?
________________________________
- \- Ата-аналарның балаларына биргән акчаны нинди акча дип атыйлар? ________________



**4. Дусларың белән фикер алыш.**

Балаларга кирәк-яракларга акча бирергә кирәкме икән?

Яхшы билге алган өчен, укыган китап, өй җыештырган һәм башка шундый гамәлләр өчен балага акча бирергә ярыймы икән?



**5. Әти-әниең белән фикер алыш. Сорауга җавап уйлап яз.**

Сүзлектән милек, милекче сүзләренең мәгънәләрен тап.

Милекче үз милкеннән ничек файдалана ала?

________________________________

________________________________


________________________________

________________________________

# 4нче класс

## «Риясызлык нәрсә ул?»


### 1нче дәрес. «Үзең өченме яки башкалар өченме?



**1. Дусларың белән түбәндәге вакыйгалар турында фикер алыш:**

1) Укучы мәктәптән кайтканда, юл кырыенда урам аркылы чыга алмыйча торган бер бабайны күргән. Малай аңа ярдәм итәргә теләп янына килгән һәм, кулыннан җитәкләп, аңа юлның икенче ягына чыгарга булышкан. Бабай рәхмәт әйтергә теләп, борылып караса, ул инде китеп тә барган.


2) Бер әби күрше малайдан кибеткә барып, аңа ипи алып кайтып бирүен үтенгән. Малай риза булган, ләкин бушка эшләмәсен белдергән.



**2.** Син беренче дәрестә әти-әниең белән бергәләп Г. Акуловның шигырен укыдың, «бескорыстный» сүзенең татар теленә тәрҗемәсен һәм аның нинди мәгънә белдерүен ачыкладың. **Хәзер син бу сүзне үзең ничек аңлыйсың? Шул турыда яз.**



**3. «Ярлы байлар» дип аталган япон халык әкиятен тыңла. Бу әкияттәге үзеңә ошаган геройларның рәсемнәрен яса. Алар сиңа ни өчен ошадылар?**




**4. Интернеттан «Болай гына» («Просто так») исемле мультфильмны тап.**



Ничек уйлыйсың, мультфильмның геройларын риясызлар дип атап буламы? Үзең шундый була аласыңмы?

Шул турыда әти-әниең белән фикер алыш.

## 2нче дәрес. «Яхшылык кылу өчен, үзеңә яхшы булырга кирәк»




**1. Сүзтезмәләрдәге сүзләрнең тамырларын тап, аерып чыгар. Тамырлардан исемнәр яса һәм язып куй.**

олы җанлы – ______________________________


киң күңел – ______________________________

игелек кылу – ______________________________

Үзең ясаган сүзләрнең мәгънәсен сүзлектән кара. Бу сүзләр күз алдыңа нинди төсләр белән күзаллана? Ни өчен?



**2. Предметларның берсен сайлап ал. Бу предмет ярдәмендә нинди игелекле гамәлләр кылырга мөмкин?**














**3. Язучы Максим Горький сүзләрен укы. Дусларың белән фикер алыш.**

«...Тирә-ягыңда яхшы күңелле, олы җанлы кешеләр булсын дисәң, үзең дә аларга игътибарлы, ягымлы бул һәм кешеләрнең күпкә яхшырак булуын күрерсең. Тормыштагы күп нәрсәләр синең үзеңнән торганын онытма».

**4. Интернеттан игелекле эшләр эшләү белән бәйле кешеләр турында мәгълүматлар тап һәм кыска гына чыгыш әзерлә.**

Әти-әниеңә, дусларыңа сөйлә.




## 3нче дәрес. Башкаларга булышып, без үзебезгә булышабыз

**1. В. А. Сухомлинскийның «Сукачы һәм сукыр тычкан» («Пахарь и Крот») исемле мәсәлен укы. Дусларың белән фикер алыш.**

Тирә-яктагы тормыш гаделрәк һәм яхшырак булсын өчен без бүген нәрсәләр эшли алабыз?

**2. Син башкалар өчен эшли ала торган яхшы эшләр пирамидасын тутыр.**



**3. Рәсемнәрне кара. Бу һөнәр ияләре кешеләр өчен нәрсәләр эшли алалар?**



**4. Киләчәктә син үзең нинди һөнәр сайларга телисең?**

---

Бу һөнәрләр өчен нинди сыйфатлар булу мөһим?

---

---

**5. Әти-әниеңнең нинди һөнәр кешеләре булуын беләсеңме? Алар ни өчен үз һөнәрләрен сайлаганнар һәм бу һөнәрләр өчен нинди сыйфатлар мөһим – әти-әниеңнән шуларны ачыкла.**

# ЭШ ДӘФТӘРЕ
## гомуми башлангыч белем бирү укучыларында коррупциягә каршы күзаллау формалаштыру буенча

Корректура, компьютерная верстка, техническое редактирование
Гиниятуллина Р. С., Некратова А. В.

Художественное оформление
Мингазова М. Ю., Федорова О. В.

Форм. бум. 60х84 1/8. Гарнитура Pragmatica.
Усл. печ. л. 3,25.

Оригинал-макет подготовлен в редакционно-издательском отделе
Института развития образования Республики Татарстан
420015 Казань, Б.Красная, 68
Тел.:(843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42
www.irort.ru, irort2011@gmail.com